СОВЕТ ПИЖМАРСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЫЖМАРА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ 30.06.2021 ел

КАРАР №26

**Пыжмара авыл җирлегенең 18 декабрь 2020 елда кабул ителгән 14 номерлы “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022 – 2023 елларның планлы чорына бюджеты турында” карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында.**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советы 2021 елга Пыжмара авыл җирлеге бюджетына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында авыл җирлегенең баш хисапчысы мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының «Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022 – 2023 еллар план чорына бюджеты турында» 2020 елның 18 декабрендәге 14 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә»:

1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге бюджетының фаразланыла торган керем күләме 4773,780 сум;

2) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 4457,408 сум.

3) бюджет чыгымнары күләмен 2021 елның 1 гыйнварына Пыжмара авыл җирлегенең исәп-хисап счетындагы ирекле калдык исәбенә арттырырга;

4) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең бюджет дефициты 316,37 сум күләмендә».

2. 1,3,7,9 нчы кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatar.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында күрсәтергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Җәләев